Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Борискино авылы башкарма комитеты

КАРАР №_1_

22 апрель 2020 ел

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Борискино авыл җирлегендә җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен билгеләү турында

1996 елның 12 январендәге «Җирләү һәм җирләү эше турында» 8-ФЗ номерлы, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә, 2007 елның 18 маендагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында күмү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 196 нчы номерлы карары нигезендә, Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы Әлмәт шәһәрендәге идарәсе (районара) Дәүләт учреждениесенең 2020 елның 23 гыйнварындагы ЯФ-08-01-12/361 номерлы мөрәҗәгате белән

Борискиноавылы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Борискино авыл җирлегендә җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 2020 елның 1 февраленнән 6124,86 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә, 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә.

2. «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Борискино авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын билгеләү турында» гы Борискино авылы башкарма комитетының 2019 елның 19 июнендәге _9_ номерлы карарын гамәлдән чыгарырга.

3. Әлеге карарны Әлмәт районы, Борискино авылы Үзәк урамы, 61 нче йорт; Березовка бистәсе, Үзәк урамы, 16 йорт территоиясендә урнашкан махсус мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2020 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны үз артымда калдырам.

Борискино авылы
башкарма комитеты җитәкчесе Ж.С.Илалов

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Борискино авылы башкарма
комитетының 2020 елның
22 апрелендәге _1_
карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Борискино авылы җирлегендә җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе

| №№ п/п | Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе, сум. |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 86, 77 |
| 2 | Гробны һәм күмү өчен кирәкле башка әйберләрне тапшыру | 3 516,70 |
| 3 | Мәрхүмнең гәүдәсен (мәетен ) зиратка алып бару | 546,35 |
| 4 | Кабер (казу һәм күмү) | 1 975,04 |
| Барлыгы | | 6 124, 86 |

Борискино авылы
башкарма комитеты җитәкчесе Ж.С.Илалов

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Борискино авылы башкарма
комитетының 2020 елның
22 апрелендәге __1__
карарына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Борискино авылы җирлегендә җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге
нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе

| №№ п/п | Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе, сум. |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 86,77 |
| 2 | Мәетне кәфенгә төрү | 2 061,75 |
| 3 | Гробны һәм күмү өчен кирәкле башка әйберләрне тапшыру | 1 454,96 |
| 4 | Мәрхүмнең гәүдәсен ( мәетен ) зиратка алып бару | 546,35 |
| 5 | Кабер (казу һәм күмү) | 1 975,03 |
| | Барлыгы | 6 124,86 |

Борискино авылы
башкарма комитеты җитәкчесе Ж.С.Илалов